Республика Татарстан

Глава Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башлыгы

РАСПОРЯЖЕНИЕ

БОЕРЫК

____14.01.2026____ Менделеевск ш. № ___2______

«Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү турында

«Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы уздырылуга бәйле рәвештә

Карар бирәм:

1. 2026 елның 19 гыйнварыннан 30 гыйнварына кадәр «Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының муниципаль этабын уздырырга.

2. «Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының муниципаль этабын уздыру өчен конкурс комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

| | |
|---|---|
| Галеева Л.К. | - Менделеевск муниципаль районы Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Метальников С.В. | - Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитыты җитәкчесе урынбасары; |
| Хорькова А.А. | - Менделеевск муниципаль районы оештыру бүлеге башлыгы урынбасары, комиссия секретаре; |
| Абдрахманова С.С. | - Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең эшләр идарәчесе, комиссия әгъзасы; |
| Искәндәрова Д.А. | - «Менделеевск» МҮ “Татмедиа” АҖ филиалы директоры, комиссия әгъзасы; (килешү буенча); |
| Сабитов Р.Х. | - Менделеевск муниципаль районы шәһәр Советы депутаты, «Төзекләндерү» МБУ директоры, комиссия әгъзасы. |

3. Республика конкурсының муниципаль этабын уздыру буенча конкурс комиссиясе тарафыннан 2026 елның 2 февраленнән 6 февраленә кадәр конкурсның II этабында катнашуга дәгъва кылучыларны билгеләргә һәм гаризаларны бәяләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы башлыгы урынбасары Л. К. Галиевага йөкләргә.

Район башлыгы Р.Р. Искәндәров